| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.03.2023 г. Заинск № 172

**«Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2018 елның 06 мартындагы 360 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

## карар бирә:

1. Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымта нигезендә расларга.
2. Үз көчен югалткан дип танырга:
2.1. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының “Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 2021 елның 9 сентябрендәге 553 номерлы карарын;
2.2. “Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 2021 елның 9 сентябрендәге 553 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 11 апрелендәге 175 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын.
3. Әлеге карарны Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.
4. Карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Р.Р. Исламова
3-47-87

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның «10» 03
172 номерлы карарына
кушымта.

## Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба - регламент) төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен (алга таба - муниципаль хезмәт) билгели.

1.2. Муниципаль хезмәтне алучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба-мөрәҗәгать итүче).

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат җиткерү:

1.3.1. муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат урнаштырыла:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре биналарында урнашкан муниципаль хезмәт күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүмат стендларында;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге муниципаль районның рәсми сайтында (https://www.zainsk.tatarstan.ru);

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба - республика порталы);

4) бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (https:/ www.gosuslugi.ru/) (алга таба - бердәм портал);

5) «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.tatar.ru) (алга таба - республика реестры).

1.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча консультацияләр бирү гамәлгә ашырыла:

1) телдән мөрәҗәгать иткәндә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә - шәхсән яисә телефон аша;

2) республика порталының интерактив формасында;

3) Зәй муниципаль районы (яки шәһәр округының) Башкарма комитетында (алга таба - Башкарма комитет):

телдән мөрәҗәгать иткәндә - шәхсән яисә телефоннан;

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазьдә язып, почта аша, электрон рәвештә – электрон почта аша.

1.3.3. Бердәм порталда, республика порталында муниципаль хезмәт күрсәтүнең тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат республика реестрындагы белешмәләр нигезендә мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка мөрәҗәгать итүче нинди дә булса таләпләрне үтәмичә керә ала, шул исәптән, мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштыру түләү алуны, мөрәҗәгать

итүчене теркәү яки авторизацияләүне, яки аларга шәхси мәгълүматларны бирүне күздә тоткан, лицензия яки башка программа белән тәэмин итү хокукына ия булучы белән килешү төзүне таләп итә торган программа тәэмин ителешен кулланмый гына.

1.3.4. Шәхсән килгәндә яки телефон аша мөрәҗәгать иткән очракта, кергән мөрәҗәгать нигезендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, Башкарма комитет (адрес, эш графигы, белешмә телефоннары) урнашкан урын турында; муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында, гаризалар бирү ысуллары һәм сроклары турында; муниципаль хезмәт күрсәтелә торган гражданнар категорияләре турында; муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләрен җайга сала торган норматив хокукый актлар турында; муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны карау өчен кирәкле документларның исемлеге, гаризаны кабул итү һәм теркәү сроклары турында; муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында; муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүматның рәсми сайтта урнашу урыны турында; Башкарма комитет вазыйфаи затларының гамәлләренә яки гамәл кылмауларына карата шикаять белдерү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат бирелергә мөмкин.

Язмача мөрәҗәгать буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы бүлекнең вазыйфаи затлары мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен һәм регламентның әлеге пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне язмача рәвештә аңлаталар һәм мөрәҗәгатьне теркәгәннән соң өч эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрәләр. Җаваплар мөрәҗәгать иткән телдә бирелә. Мөрәҗәгать иткән телдә җавап бирү мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт телләре файдаланыла.

1.3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат муниципаль районның (яисә шәһәр округының) рәсми сайтында һәм Башкарма комитет биналарындагы мөрәҗәгать итүчеләр белән эш алып бару буенча мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

Башкарма комитет биналарында урнашкан мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүмат стендларында, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге муниципаль районның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат шушы регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларында) муниципаль хезмәт турында белешмәләрне, Башкарма комитетның урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш вакыты, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гаризалар кабул итү графигы турында мәгълүматны үз эченә ала.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге муниципаль районның рәсми сайтында, республика реестрында урнаштырылган.

Административ регламентның гамәлдәге редакциясендәге тексты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге муниципаль районның рәсми сайтында, республика реестрында урнаштырылырга тиеш.

1.5. Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- мөрәҗәгать итүче - дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органга яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органга, яисә 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы 2 һәм 3 өлешләрендә күрсәтелгән оешмаларга яисә 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясы 5 пунктында күрсәтелгән оешмаларга дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә белән, шул исәптән 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә телдән, язмача яисә электрон формада мөрәҗәгать иткән физик яисә юридик зат (дәүләт органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан тыш) яисә аларның вәкаләтле вәкилләре;

- төзүче - үзенә караган җир кишәрлегендә яисә башка хокук иясенең җир кишәрлегендә (аңа дәүләт (муниципаль) милкендәге капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда "Росатом" атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, "Роскосмос" космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары яки җирле үзидарә органнары килешүләр нигезендә дәүләт (муниципаль) заказчысы вәкаләтләрен тапшырган яки «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясы нигезендә дәүләт (муниципаль) заказчысының үз вәкаләтләрен тапшырган очракларда) капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны, капиталь ремонтлауны, капиталь объектларны сүтү, шулай ук инженерлык эзләнүләрен башкаруны, әлеге объектларны төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау өчен проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы физик яисә юридик зат. Төзүче шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнарда каралган үз функцияләрен техник заказчыга тапшырырга хокуклы;

- техник заказчы - төзүче тарафыннан вәкаләт бирелгән һәм төзүче исеменнән инженер тикшеренүләрен башкару, проект документларын әзерләү, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, аларны сүтү турында килешүләр төзү, күрсәтелгән эшләр төрләрен үтәүгә биремнәр әзерләү, проект документациясен әзерләүне, капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне, капиталь ремонтлауны гамәлгә ашыручы затларга тапшыра, күрсәтелгән эшләр төрләрен башкару өчен кирәкле документлар һәм документлар раслау, капиталь төзелеш объектын файдалануга кертүгә рөхсәт алу өчен кирәкле документларга кул кую, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарда каралган башка функцияләрне (алга таба шулай ук - техник заказчы функцияләрен) гамәлгә ашыручы юридик зат. Техник заказчы функцияләре бары тик инженерлык эзләнүләре, архитектура-төзелеш проектлау, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау өлкәсендә үз-үзен җайга сала торган оешма

әгъзасы тарафыннан гына үтәлергә мөмкин, моңа РФ Шәһәр төзелеше кодексының 47 статьясы 1 өлешендә, 48 статьясы 4 өлешендә, 52 статьясы 2 өлешендә, 52 статьясы 2 өлешендә каралган очраклар керми.

Төзелешкә рөхсәт капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проектында каралган бөтен срокка бирелә, моңа мондый рөхсәт төзелешнең, реконструкциянең аерым этапларына бирелгән очраклар керми. Шәхси торак төзелешенә рөхсәт ун елга бирелә.

Төзелешкә рөхсәт бирү срогы төзүченең мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакыты чыкканга кадәр кимендә ун көн алдан бирелгән гаризасы буенча озайтылырга мөмкин. Капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү мондый гариза бирү вакыты чыкканчы башланмаган очракта, төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайтудан баш тартыла.

Төзелешкә рөхсәт бирү түбәндәге очракларда таләп ителми:

1) эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле булмаган максатлар өчен физик затка бирелгән җир кишәрлегендә гараж төзү, реконструкцияләү яисә бакчачылык һәм яшелчәчелек өлкәсендәге законнар нигезендә билгеләнгән бакча җир кишәрлегендә торак йорт, бакча йорты, хуҗалык корылмалары төзү, реконструкцияләү;

1.1) индивидуаль торак төзелеше объектларын төзү, реконструкцияләү («Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзүдән тыш);

2) капиталь төзелеш объекты булмаган объектларны (киосклар, навеслар һәм башкалар) төзү, реконструкцияләү;

3) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган критерийга кертелгән җир участогында ярдәмче файдаланудагы төзелмәләр һәм корылмалар төзү;

4) капиталь төзелеш объектларын һәм (яисә) аларның өлешләрен үзгәртү, әгәр мондый үзгәрешләр аларның ышанычлылыгына һәм куркынычсызлыгына, конструктив һәм башка характеристикаларга кагылмаса һәм рөхсәт ителгән төзелешнең, шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан артмаса;

4.1) капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау, шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясының 11 өлешендә күрсәтелгән очракта;

5) шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе субъектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнары нигезендә төзелешкә рөхсәт алу таләп ителмәгән башка очракларда.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны - "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында" 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлегендә һәм шәһәр округында төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең (офис) территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офис);

- техник хата - муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән хата һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, шуларга нигезләнеп кертелгән документлардагы белешмәләрнең туры килмәвенә китергән хата (описка, опечатка, грамматик яки арифметик хата яки шуларга охшаш хаталар).

- ЕСИА – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла һәм мәгълүмати-технологик үзара бәйләнешне тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификациянең бердәм системасы.

Дәүләт мәгълүмат системаларында һәм башка мәгълүмат системаларында булган мәгълүматтан мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыларның (мөрәҗәгать итүчеләрнең һәм башкарма хакимият органнарының һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларының) мәгълүмат алу мөмкинлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

- КФҮ (МФЦ) - «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципальхезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе;

КФҮ АМСы (АИС) - Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы.

Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза) дигәндә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясы 3 пункты нигезендә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамә аңлашыла (алга таба – 210 номерлы Федераль закон).

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

2.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең атамасы

Төзелешкә рөхсәт бирү.

2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә башкарма-боеру органының исеме

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты.

2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

2.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып тора:

1) төзелешкә рөхсәт бирү (2 нче кушымта);

2) төзелешкә рөхсәтнең дубликатын бирү;

3) төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар.

2.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә Башкарма комитет вазыйфаи затының «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә көчәйтелгән квалификацияле имзасы куелган электрон документ рәвешендә республика порталының шәхси кабинетына җибәрелә.

2.3.3. Мөрәҗәгать итүченең теләге буенча Башкарма комитет тарафыннан җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе КФҮдән электрон документның КФҮ мөһере һәм КФҮ хезмәткәре имзасы белән расланган кәгазь чыганакта бастырылган нөсхәсе рәвешендә алынырга мөмкин.

2.3.4. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ яисә электрон документның кәгазь чыганактагы нөсхәсе рәвешендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу срогы дәвамында алырга хокуклы.

2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору вакыты, әгәр Россия Федерациясе законнарында каралган булса, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) вакыты

2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты:

Төзелешкә рөхсәт бирү - гариза бирү көнен дә кертеп, биш эш көне. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты гаризаны теркәгәннән соң икенче көнне исәпләнә башлый.

Төзелешкә рөхсәт вакытын озайту - биш эш көне.

Төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү - җиде эш көне.

Төзелешкә рөхсәт дубликатын бирү - өч эш көне.

2.4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.4.3. Электрон документ формасында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документны җибәрү муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен закон чыгаручы яки бүтән норматив хокукый актлар нигезендә зарури документларның, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә тиешле хезмәтләрнең, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу, шул исәптән электрон рәвештә, бирү ысулларының тулы исемлеге

2.5.1. Капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору очрагында мөрәҗәгать итүче тәкъдим итә:

1) гариза:

-кәгазь документ формасында;

- региональ портал аша мөрәҗәгать иткәндә, «Электрон имза турында» 2011 елның 06 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада;

2) җир кишәрлегенә хокук Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән очракта, җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар, шул исәптән сервитут билгеләү турында килешү, гавами сервитутны билгеләү турында карар, шулай ук күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелгән һәм РФ Шәһәр төзелеше кодексының 57.3 статьясындагы 1 өлеше белән каралган очракта, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 57.3 статьясындагы 7.3 өлеше белән башкасы билгеләнмәгән очракта, җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы бирелгән территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасы;

3) Россия Федерациясе Бюджет законнары белән билгеләнгән очракларда дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе "Росатом", космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе "Роскосмос", бюджеттан тыш дәүләт фонды белән идарә итү органы яки җирле үзидарә органы тарафыннан бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда төзелгән дәүләт (муниципаль) заказчының вәкаләтләрен тапшыру турында килешү булганда - күрсәтелгән килешү, килешү төзелгән хокук иясенең җир кишәрлегенә хокукын билгели торган документлар;

4) төзелешкә рөхсәт алуга гариза бирелгән көнгә кадәр өч елдан да иртәрәк булмаган вакытта бирелгән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы яисә линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты реквизитлары (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру документларын әзерләү таләп ителмәгән очраклардан тыш), урнаштыру өчен җир кишәрлеге төзү таләп ителми торган линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта территорияне планлаштыру проекты реквизитлары;

5) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре һәм РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының 15 өлешенә ярашлы рәвештә расланган проект документациясендә булган түбәндәге материаллар:

а) аңлатма язуы;

б) җир участогының шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүматка ярашлы рәвештә башкарылган җир участогын планлаштыру оешмасы схемасы, ә проект документациясен линия объектларына карата әзерләгән очракта территорияне планлаштыру проектына ярашлы башкарылган бүлеп бирү полосасы проекты (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителмәгән очраклардан тыш);

в) архитектур һәм конструктив чишелешләр, шулай ук инвалидларның капиталь төзелеш объектына керүен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар булган бүлекләр (сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт һәм башка социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш объектларына, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга, торак фонды объектларына карата проект документлары әзерләнгән очракта);

г) капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты (капиталь төзелеш объектларын, капиталь төзелеш объектларын сүтү кирәк булган очракта аларның

өлешләрен, башка капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү өчен аларның өлешләрен сүтү буенча эшләрне оештыру проектын кертеп);

6) әгәр мондый проект документларына РФ Шәһәр төзелеше кодексның 49 статьясы нигезендә экспертиза ясалырга тиеш булса, капиталь төзелеш объектының проект документларына ясалган уңай экспертиза бәяләмәсе (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясындагы 12.1 өлешендә каралган очракта төзелешнең аерым этапларына, линияле объектларны да кертеп, карата), РФ Шәһәр төзелеше кодексның 49 статьясындагы 3.4 өлешендә каралган очракларда дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе, РФ Шәһәр төзелеше кодексның 49 статьясындагы 6 өлешендә каралган очракларда проект документларына дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсе (әгәр әлеге документлар (аларның күчермәләре яки алардагы мәгълүматлар) Белешмәләрнең бердәм дәүләт реестрында булмаса);

6.1) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.8 өлеше нигезендә проект документациясенә үзгәрешләр кертелгән очракта проект документациясен әзерләүне гамәлгә ашыручы затлар әгъзалыгына нигезләнгән үз-үзен җайга сала торган оешма әгъзасы булып торучы зат тарафыннан бирелгән һәм әлеге кодекс нигезендә җәлеп ителгән зат тарафыннан проектның баш инженеры вазыйфасында архитектур-төзелеш проектлаштыруны оештыру буенча белгеч тарафыннан расланган проект документациясенә кертелә торган үзгәрешләрнең РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.8 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау;

6.2) проект документациясенә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.9 өлеше нигезендә экспертиза эшләре барышында үзгәрешләр кертелгән очракта проект документациясенә экспертиза үткәргән башкарма хакимият органы яки оешма тарафыннан бирелгән проект документациясенә кертелә торган үзгәрешләрнең РФ шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 3.9 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау;

7) рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт (төзүчегә РФ Шәһәр төзелеше кодексының 40 статьясы нигезендә мондый рөхсәт бирелгән очракта);

7.1) әгәр мондый килештерү РФ Шәһәр төзелеше кодексының 40.1 статьясында каралган булса, капиталь төзелеш объектының архитектур-шәһәр төзелеше күренешен килештерү;

8) мондый объектны үзгәртеп корган очракта, капиталь төзелеш объектының барлык хокук ияләренең, күпфатирлы йортны реконструкцияләүнең 6.2 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, ризалыгы, блоклы төзелеш йортларының берсен реконструкцияләгән очракта, бер рәттән барлык йортларның да хокук ияләренең ризалыгы;

8.1) дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), "Росатом" атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, "Роскосмос" космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджеттан тыш фонд белән идарә итү органы яки җирле үзидарә органы булган дәүләт (муниципаль) заказ бирүче тарафыннан аңа карата күрсәтелгән орган тиешенчә оештыручы функцияләрен һәм вәкаләтләрен яисә

мөлкәт милекчесенең хокукларын гамәлгә ашыра торган хокук иясе дәүләт (муниципаль) унитар предприятиесе, дәүләт (муниципаль) бюджет яисә автоном учреждениесе булган дәүләт (муниципаль) милкендәге капиталь төзелеш объектын реконструкцияләүне уздырган очракта, - реконструкцияләү үткәргәндә күрсәтелгән объектка китерелгән зыянны каплау шартларын һәм тәртибен билгели торган мондый реконструкция үткәрү турында килешү;

8.2) күпфатирлы йорттагы биналар һәм машина урыннары хуҗаларының күпфатирлы йортны реконструкцияләгәндә торак законнары нигезендә кабул ителгән гомуми җыелышы карары яки, әгәр мондый реконструкция нәтиҗәсендә күпфатирлы йортта гомуми милек күләме кимесә, күпфатирлы йорттагы барлык биналар һәм машина урыннары хуҗалары ризалыгы;

9) мәдәни мирас объектларын саклап калу эшләрен уздырганда мондый объектның ышанычлылыгына һәм иминлегенә башка характеристикаларына кагылган очракта, мәдәни мирас объектлары турында Россия Федерациясе законнарында каралган документлар;

10) капиталь төзелеш объекты төзелгән очракта, аны урнаштыру белән бәйле рәвештә Россия Федерациясе законнарына ярашлы рәвештә территорияне куллануның аерым шартлары булган зона булдырылырга яки капиталь төзелеш объектын реконструкцияләгәндә, нәтиҗәдә реконструкцияләнгән объектка карата территорияне куллануның махсус шартлары булган зона яки элек билгеләнгән территорияне куллануның аерым шартлары булган зона үзгәртелергә тиеш булганда территорияне куллануның махсус шартлары булган зонаны билгеләү яки үзгәртү турында карар күчермәсе;

11) җирле үзидарә органы территорияне комплексլы үстерү турында карар кабул иткән территория чикләрендә капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү планлаштырылган очракта, территорияне үстерү турында килешү күчермәсе (Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты яки муниципаль берәмлек тарафыннан территорияне комплекслы үстерү яки мондый карарны Россия Федерациясенең әлеге кодексына яки Россия Федерациясе субъектына ярашлы билгеләнгән юридик зат тарафыннан гамәлгә ашыру турында карарны мөстәкыйль гамәлгә ашыру очракларыннан тыш).

2.5.2. Рөхсәт срогын озайтканда мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:

1) төзелешкә рөхсәт бирү вакытын озайту турында гариза (төзелешкә рөхсәт бирү вакыты чыкканчы кимендә 60 календарь көн алдан бирелә).

Төзелешкә рөхсәт бирү вакытын озайту турында гариза торак урынны тапшыруны күздә тоткан өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе нигезендә күпфатирлы йортны һәм (яисә) башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешле төзү өчен гражданнарның һәм юридик затларның акчаларын җәлеп итүче төзүче тарафыннан бирелгән очракта, мондый гаризага йорт салучы тарафыннан өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе яисә күпфатирлы йортны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын (төзүче) өлешле төзү өчен акчалар җәлеп итүче затның гражданлык җаваплылыгын иминләштерү шартнамәсе буенча торак урынны тапшыру йөкләмәләрен тиешенчә үтәгән өчен банкның җаваплылыкны үз өстенә алу шартнамәсе теркәп бирелергә тиеш.

2.5.3. Төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр керткәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:

Мөрәҗәгать итүчегә җир кишәрлекләренә хокукларны, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын күчерү, җир участогы төзү турында, реквизитларны күрсәтеп, язмача хәбәрнамә:

1) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясы 21.5 өлешендә күрсәтелгән очракта, мондый җир кишәрлекләренә хокукны билгели торган документлар;

2) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясы 21.6 һәм 21.7 өлешләрендә каралган очракларда җир кишәрлекләрен төзү турында карар, әгәр җир законнары нигезендә җир кишәрлеген төзү турында карар дәүләт хакимиятенең башкарма органы яисә җирле үзидарә органы тарфыннан кабул ителсә;

3) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясы 21.7 өлешендә каралган очракта капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү планлаштырыла торган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы;

4) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясы 21.9 өлешендә каралган очракта җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында карарлар;

5) капиталь төзелеш объектын төзегән очракта территориядән файдалануның махсус шартлары булган зонаны билгеләү яки үзгәртү турында карар күчермәсе, анда Россия Федерациясе законнары нигезендә, территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона билгеләнергә, яки капиталь төзелеш объектын үзгәртеп корганда, аның нәтиҗәсендә реконструкцияләнгән объектка карата территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона билгеләнергә яисә элегрәк билгеләнгән территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона үзгәртелергә тиеш.

2.5.4. Рөхсәт дубликатын биргәндә гариза бирүче тәкъдим итә:

1) гариза;

2) шәхесне яки вәкаләтне раслый торган документлар.

2.5.5. Гариза һәм кушып бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

1) КФҮ аша кәгазьдә һәм регламентның 2.5.6 пункты таләпләренә туры китереп имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә;

2) республика порталы аша электрон формада.

2.5.6. Физик затлар һәм шәхси эшкуарлар гариза һәм кирәкле документларны бердәм портал, республика порталы аша җибәргәндә гаризаны гади электрон имза белән имзалыйлар.

Гади электрон имза алу өчен мөрәҗәгать итүчегә ЕСИАда теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук хисап язуын стандарттан түбән булмаган дәрәҗәгә кадәр расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик затлар вәкилләре бердәм портал, республика порталы ярдәмендә гариза һәм

кирәкле документлар җибәргәндә, гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

Соратуны республика порталы аша җибәргәндә, мөрәҗәгать итүче документларның электрон үрнәкләрен яисә 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп, әлеге документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затлар, шул исәптән нотариуслар тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документларны электрон формада тапшыра.

2.5.7. Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яисә гамәлләрне башкару каралмаган документларны һәм мәгълүматны бирү, гамәлләр башкару;

2) гамәлләр, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле һәм башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга мөрәҗәгать итү белән бәйле булган һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле булган килештерүләрне башкару, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән исемлеккә кертелгән хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсендә бирелә торган хезмәт күрсәтүләрдән, документлар һәм мәгълүмат алудан тыш (кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр);

3) түбәндәге очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренчел баш тарткан вакытта документларның булмавы һәм (яисә) дөрес түгеллеге турында хәбәр ителмәгән документлар яисә мәгълүмат бирүне:

а) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны беренче тапкыр биргәннән соң муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләрен үзгәрүе;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризада һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренчел баш тартканнан соң бирелгән һәм элек бирелгән документлар комплектына кертелмәгән документларда хаталар булу;

в) документларның гамәлдә булу вакыты тәмамлану яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренчел баш тартканнан соң мәгълүматның үзгәрүе;

г) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренчел баш тарткан очракта, Башкарма комитетның вазыйфаи затының, КФҮ хезмәткәренең хаталы яки хокукка каршы гамәлләре (гамәл кылмавы) фактын (билгеләрен) ачыклау, бу хакта муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тарткан очракта Башкарма комитет җитәкчесе имзасы белән язма рәвештә мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр;

4) басма чыганактагы электрон үрнәкләре 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә расланган

документларны һәм мәгълүматны басма чыганакта тапшыру, мондый документларга тамгалар кую яисә аларны алу дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары ведомство буйсынуында булган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма

2.6.1. Шәхси торак төзелеше объектлары булмаган объектларга рөхсәт бирелгән очракта, түбәндәге документлар (белешмәләр) соратып алына:

1) күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар (күчемсез милек объектының төп характеристикалары һәм теркәлгән хокуклары турында белешмәләр) - Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте (Росреестр);

2) бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда төзелгән Россия Федерациясе бюджет законнарында, дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), "Росатом" атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, "Роскосмос" космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе, бюджеттан тыш дәүләт фонды идарәсе органы яисә җирле үзидарә органы тарафыннан дәүләт (муниципаль) заказчысы вәкаләтләрен тапшыру турында килешү;

3) төзелеш өчен рөхсәт алуга гариза бирелгән көнгә кадәр өч елдан да иртәрәк булмаган срокта бирелгән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы, яисә линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты реквизитлары;

4) рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкциянең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт (төзүчегә РФ Шәһәр төзелеше кодексының 40 статьясы нигезендә мондый рөхсәт бирелгән очракта);

5) тәңгәллек сертификатларының бердәм реестрыннан белешмәләр;

6) проект документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе;

7) проект документациясендәге материаллар.

2.6.2. Төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертелгән очракта (кертелгән үзгәрешләргә карап) түбәндәге документлар (белешмәләр) соратып алына:

1) күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем файдалана алырлык мәгълүмат булган);

2) әгәр җир законнары нигезендә җир кишәрлеген төзү турында карар дәүләт хакимиятенең башкарма органы яисә җирле үзидарә органы тарафыннан кабул ителсә, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 21.6 һәм 21.7 өлешләрендә каралган очракларда җир кишәрлекләрен төзү турында карар;